**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

**егерме өченче утырыш**

**4 октябрь 2023 ел** **№104** **Теләче ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советынын 2014 елның 27нче ноябрендәге 163 номерлы «Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте.

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2014 елның 27нче ноябрендәге 163 номерлы «Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Күрсәтелгән карар белән расланган, Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында Нигезләмәгә:

А) 16 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, яисә үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү, хатынының (иренен) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, белә торып тулы

булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яки, белә торып хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында ялган белешмәләр бирү, әгәр мондый мәгълүматны тапшыру мәҗбүри булса, муниципаль хезмәткәрләрне алмаштырып торган (биләгән) вазифаларыннан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Хаҗипов